**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

**2015 елның «18» мартыннан** **№ 42-247**

**««Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Уставын яңа редакциядә кабул итү турында»**

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 29 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Уставын яңа редакциядә кабул итәргә (кушымтада бирелә).
2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.
5. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән гамәлдәге законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып кабул ителде.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль район Башлыгы** **В. М. Козлов**